СОВЕТ ЗИРЕКЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 53,
с. Ерыклы, 423185

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЗИРЕКЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Ленин урамы, 53,
Зирекле авылы, 423185

тел., факс: (8-4348) 38-6-76, zarek.nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
Зирекле авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2022 елның "26" апреленнән № 20-64

## Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең муниципаль норматив хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) чыганаклары турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең муниципаль хокукый актларын бастырып чыгаруның (халыкка җиткерүнең) рәсми чыганаклары итеп билгеләргә:

- районда таратыла торган вакытлы басма «Яңа Чишмә хәбәрләре» газетасы: www.novoshishminsk.ru;

- Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайты Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http://novosheshminsk.tatarstan.ru/;

- «Россия Федерациясендә норматив хокукый актлар» Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы порталы: http://pravo-minjust.ru, http://право-минюст.рф «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә;

- «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»: http://pravo.tatarstan.ru;

- кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге торак пункты территориясендә махсус мәгълүмат стендлары;

- Зирекле авыл җирлегендә яшәүчеләргә хокукый акт текстын үзәкләштерелгән тәртиптә, шул исәптән махсус басма рәвешендә тарату.

2. Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге Советының 2005 елның 21 октябрендәге 1-5 нче номерлы «Зирекле авыл җирлеге Советының муниципаль хокукый актларын халыкка җиткерү турында»гы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatrstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге Советының законлылык, экология, җирдән файдалану, торак - коммуналь хуҗалык һәм территорияне төзекләндерү буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Зирекле авыл җирлеге башлыгы — Җ.Г. Гайфетдинов

СОВЕТ ЗИРЕКЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Кушымта
Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Зирекле авыл җирлеге
Советының 26 апреленнән
2022 елның 20-64 номерлы
карарына

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актлары текстларын урнаштыру өчен махсус мәгълүмат стендлары исемлеге

| Агитацион басма материаллар элү өчен махсус урын адресы | Элү урынының исеме (махсус җиһазландырылган конструкция, мәгълүмат стенды (реклама щиты, тумба), стенд (бина диварындагы игъланнар тактасы, фойеда һ. б.) | Саны, шт. |
|---|---|---|
| ТР Яңа Чишмә муниципаль районы, Зирекле авылы, Ленин ур., 53 йорт | Махсус мәгълүмат стенды | 1 |
| ТР Яңа Чишмә муниципаль районы, Зирекле авылы, Ленин ур., 68 йорт | Махсус мәгълүмат стенды | 1 |
| ТР Яңа Чишмә муниципаль районы, Өргәнче авылы, Яңа ур., 5 йорт | Махсус мәгълүмат стенды | 1 |